| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
|---|---|---|
| Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района | | Менделеев муниципаль районы башкарма комитеты |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.04.2026 г. Менделеевск № 291

Менделеевск муниципаль
районында ягулык сезонын
тәмамлау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 6 маендагы 354 нче номерлы карары белән расланган гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең 5 пункты, Россия Федерациясе дәүләт төзелешенең «Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2003 елның 27 сентябрендәге 170 нче номерлы карары нигезендә һәм биш тәүлек эчендә билгеләнгән уртача тәүлеклек һава температурасы +8 градус Цельсий һәм югарырак булганда, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "Таткоммунэнерго" республика җитештерү берләшмәсе" акционерлык җәмгыятенә, профсоюзларның шәхси дәвалау-профилактика учреждениесе “Шифалы Су-Ижминводы " шифаханәсенә һәм районның авыл җирлекләре башлыкларына торак йортларга җылылык бирүне 2026 елның 4 маеннан башлап туктатырга тәкъдим итәргә.

1.1 Менделеевск муниципаль районының социаль-көнкүреш билгеләнешендәге объектларына җылылык бирүне туктатырга:

- спорт объектлары 2026 елның 4 маеннан;
- Менделеевск муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитетының административ биналары 2026 елның 4 маеннан;
- “Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе” МКУ 2026 елның 4 маеннан, "Этюд" яшь тамашачы театры объектлары 2026 елның 7 маеннан;
- «Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ объектлары 2026 елның 7 маеннан;
- «Менделеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ объектлары 2026 елның 4 маеннан, стационар бүлек 2026 елның 7 маеннан.

2. Җылылык белән тәэмин итүче һәм хезмәт күрсәтүче оешмаларга киңәш итәргә:

2.1. Җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык куллану объектларын 2026-2027 еллар ягулык чорына әзерләү план-графикларын эшләргә һәм расларга һәм күчермәләрен Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетына 2026 елның 15 маена кадәр тапшырырга.

2.1. 2026-2027 еллар ягулык чорына җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык кулланy объектларын әзерләүне 2026 елның 18 маеннан башларга.

2.2. Атна саен 2026 елның 19 маеннан башлап һәр сишәмбе Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетына җылылык һәм җылылык куллану объектларында әзерлек эшләренең барышы турында оператив хисап тапшырырга.

3. "Таткоммунэнерго" республика җитештерү берләшмәсе" акционерлык җәмгыятенә, профсоюзларның шәхси дәвалау-профилактика учреждениесе “Шифалы Су-Ижминводы " шифаханәсенә кискен суыту очрагында җылылык чыганакларының һәм җылылык белән тәэмин итү системаларының, беренче чиратта, сәламәтлек саклау объектларына һәм мәктәпкәчә балалар учреждениеләренә җылылык энергиясен бирүгә әзерлеген тәэмин итәргә.

4. Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының “ Менделеевск муниципаль районында ягулык сезонын тәмамлау турында " 2025 елның 18 апрелендәге 278 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы С.В.Метальников